**Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Азнакай район Советы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 140-16 «14» апрель 2022 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советының 2013 елның 22 октябрендәге 267-37 номерлы «Бюджет даирәсендә эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре таралмый тоорган, муниципаль берәмлекләр башлыкларының, депутатларның, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының, Азнакай муниципаль районы контроль-хисап палатасы рәисенең акчалата түләү күләмнәрен, муниципаль хезмәткәрләрнең айлык вазыйфаи окладларын һәм бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын индексацияләү турында»

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 30 мартындагы 694 номерлы "Бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре таратылмый торган бюджет өлкәсе аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын 2013 елның 1 октябреннән арттыру турында" карары үз көчен югалткан дип тануны исәпкә алып,Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 30 мартындагы 694 номерлы "Бюджет даирәсендә эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре таралмый торган, бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» карары кабул ителүгә бәйле рәвештә,

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай район Советының түбәндәге крарары үз көчен югалткан дип танырга:

- 2013елның 22 октябрендәге 267-37 номерлы "Бюджет даирәсендә эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре таралмый тоорган, муниципаль берәмлекләр башлыкларының, депутатларның, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының, Азнакай муниципаль районы контроль-хисап палатасы рәисенең акчалата түләү күләмнәрен, муниципаль хезмәткәрләрнең айлык вазыйфаи окладларын һәм бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын индексацияләү турында».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru//. http://pravo.tatarstan.ru

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет, салымнар, финанс һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.З. Шәйдуллин